**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**21.11.2014** **№ 01-02/495**

Казан шәһәре

“Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасы һәм кадрлар составы үзгәрүгә бәйле рәвештә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта “Столяров С.Н.” сүзләрен “Заһидуллин Р.И.” сүзләренә алмаштырырга.

2. “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгы белән расланган административ регламентына (22.10.2013 № 01-02/130, 19.08.2014 № 01-02/312 боерыклар белән кертелгән үзгәрешләре белән) (алга

таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3.1 пунктта:

беренче абзацта “Кремль ур., 16.” сүзләрен “Татарстан урамы, 55.” сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җәмәгать транспортында “Кәрим Тинчурин урамы” тукталышына кадәр барырга:

автобуслар №№ 1, 6, 31, 53, 54, 71, 99;

троллейбуслар№№ 3, 5;

трамвай № 2.”;

1.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3.2. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 293-07-81; 223-01-57.”;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.4. Дәүләт хезмәт күрсәтүләре түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында”2010 елның 27 июлендәге№ 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) белән (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән;

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында” 2005 елның 6 апрелендәге № 64-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – № 64-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), ст. 344, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән;

“Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) исемнәрендә куллануга юридик затларга рөхсәтләр бирү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.04.2004 № 179 карары (алга таба – ТРМКның № 179 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каралары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив хокукый актлары җыентыгы, 21.04.2004, № 16, ст. 0356) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән;

“Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) исемнәрендә куллануга юридик затларга рөхсәтләр бирү турындагы гаризаларны карау тәртибе хакында “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) исемнәрендә куллануга юридик затларга рөхсәтләр бирү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.04.2004 № 179 карары белән расланган нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каралары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма

хакимияте органнары норматив хокукый актлары җыентыгы, 21.04.2004, № 16, ст. 0356, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән;

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.02.2006 № 68 карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каралары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив хокукый актлары җыентыгы, 07.03.2006, № 10, ст. 0272, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән;

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламентын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 № 880 карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каралары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив хокукый актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән”;

2 бүлекнең 2.14 пунктының икенче баганасындагы “420503, Казан шәһәре, Кремль ур, 16.” сүзләрен “420021, Казан шәһәре, Татарстан урамы, 55.” сүзләренә алмаштырырга;

3 нче бүлектә:

3.3.2 пунктта “Министрлыкның документлар әйләнеше һәм эшләр алып бару секторы (алга таба – Сектор)” сүзләрен “оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге (алга таба – Документлар әйләнеше бүлеге)” сүзләренә алмаштырырга;

3.4.4 пунктта “Сектор” сүзен “Документлар әйләнеше бүлеге)” сүзләренә алмаштырырга”;

3.5 пунктта “Сектор” сүзен “Документлар әйләнеше бүлеге)” сүзләренә алмаштырырга”;

Блок-схемада (Административ регламентка 1 нче кушымта):

“Сектор” сүзен “Документлар әйләнеше бүлеге)” сүзләренә алмаштырырга”;

Административ регламентка кушымтадагы таблицаны (белешмә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| “Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 8(843) 293-12-23 | minjust@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 8(843) 223-06-64 | R.Zagidullin@tatar.ru |
| Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге | 8(843) 223-07-60 | V.Gizatullina@tatar.ru |
| Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция | 8(843) 223-07-81 | Elmira.Slepneva@tatar.ru” |

| | | |
|---|---|---|
| министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы | | |

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны юстиция министрының беренче урынбасары Р.И.Заһидуллинга йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова